Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай авыл җирлеге Советы
карары

2025 елның 22 сентябре №1/5

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 февралендәге 32/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 10 февралендәге 32/1 номерлы Чистай шәһәр Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 статьяның 11 пунктының 1 пунктчасының 6 абзацында «гуманитар ярдәм,» сүзләреннән соң «халыкны яклауны тәэмин итү,» сүзләрен өстәргә, «китергән» сүзләреннән соң «яисә китерергә мөмкин» сүзләрен өстәргә;

1.2. 39 статьяның 2 өлешендә «составын һәм срокларын» сүзләрен «төзү тәртибе, составы һәм сроклары һәм» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Чистай авыл җирлеге
башлыгы Р.М. Мәгъсүмов